# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Хезмәт өчен түләүнең
## минималь күләме турында

### 1 статья

1995 елның 1 сентябреннән хезмәт өчен түләүнең минималь күләмен айга 200 мең сум итеп билгеләргә.

### 2 статья

Татарстан Республикасы законнары нигезендә салынучы салымнар, җыемнар, эшсезлек буенча пособиеләр, административ штрафлар, зыян каплау һәм башка түләүләр хезмәт өчен түләүнең Россия Федерациясендә гамәлдә булган минималь күләменнән чыгып исәпләнелә.

Хезмәт өчен түләүнең нормалаштырылган күләмен арттырган өчен салым Россия Федерациясендә билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең сигез минималь күләменнән чыгып исәпләнелә.

### 3 статья

Россия Федерациясе законнары нигезендә салына торган дәүләт пошлинасы, штрафлар һәм башка түләүләр хезмәт өчен түләүнең Россия Федерациясендә гамәлдә булган минималь күләменнән чыгып башкарыла.

### 4 статья

Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына әлеге Законда каралган чараларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау тәртибен һәм чыганакларын билгеләргә.

**5 статья**

"Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында" 1995 елның 17 гыйнварендагы Татарстан Республикасы Законы үз көчен югалткан дип санарга.

**6 статья**

Әлеге Законны 1995 елның 1 сентябреннән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1995 елның 13 сентябре

№230